**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы**
**Күәм авыл җирлеге**

422740, Әтнә муниципаль районы
Күәм авылы,Х.Такташ урамы, 1,1003 б
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Атнинский муниципальный район**
**Кубянское сельское поселение**

422740, Атнинский муниципальный район
с.Кубян, ул. Х.Такташа, 1,пом.1003
тел. 3-63-39, факс 3-63-39

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

5 ноябрь 2025 ел № 7

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы , Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. 2025 елның 29 ноябренә 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Күәм авылы Х.Такташ,Космодемьянская, Л.Толстой,Лермонтов,Коммуна, Тынычлык, Тельман, Ленин урамының 1-52 нче йортларында сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2025 елның 29 ноябренә 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча, Күәм авылы Ленин урамының 53-130 йортларында,Г.Тукай, М.Җәлил, Мәктәп, Комсомол, Р.Зорге урамнарында сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- - гражданнар җыенынын беренче этабын үткәрү вакыты –29 ноябрь 2025 ел 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;
- гражданнар җыенынын икенче этабын үткәрү вакыты – 29 ноябрь 2025 ел 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр
- халык җыенының беренче этабын үткәрү урыны – Күәм авылы, Коммуна урамы, 12 нче йорт каршында;
- халык җыенының икенче этабын үткәрү урыны – Күәм авылы, Ленин урамы, 108 нче йорт каршында;

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 20 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күәм авылы, Х.Такташ урамы, 1 йорт, 1003 б;

- сайлау хокукына ия булган Күәм торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;

- гражданнар җыены турында Күәм торак пункты халкына мәгълүмат стендлары аша һәм башка ысуллар белән хәбәр итергә.

5. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

"Сез 2026 елда Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын, электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен яктырткычлар, проводлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү);

-Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Беларусь-82.1 тракторы өчен чапкыч сатып алу, Күәм авылы территориясен чистарту, агачларны, куакларны кисү, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү (Күәм авылының Космодемьянская урамындагы чишмә территориясен чистарту һәм төзекләндерү, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Күәм авылындагы урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү өчен вак таш сатып алу, хезмәтләр өчен түләү).

"РИЗА" "КАРШЫ"

6. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Күәм авылы, Х.Такташ урамы 1 нче йорт адресы буенча урнашкан стендка урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Күәм авыл җирлеге башлыгы Сәмигуллин Л.Ә.